ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 19 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән үзара эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 16-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 19 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән үзара эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 16-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 28 ноябре
№ 104-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 19 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән үзара эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 29 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының, аларның вазыйфаи затларының, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең үзара мөнәсәбәтен, Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә аларның гомуми мәнфәгатьләрен чагылдыруны һәм яклауны тәэмин итә торган «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе (алга таба – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы) төзелә.»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советын оештыру һәм аның эшчәнлеге коммерциягә карамаган оешмалар турында Россия Федерациясе

законнарының ассоциацияләргә карата кулланылучы таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

в) 3 һәм 4 өлешләрне үз көчен югалткан дип танырга;

г) 5 өлештә «муниципаль берәмлекләрнең бердәм гомумроссия берләшмәсе составына керергә мөмкин» сүзләрен «Җирле үзидарәне үстерү бөтенроссия ассоциациясе» ассоциациясе әгъзасы булып тора» сүзләренә алмаштырырга;

е) 6 өлештә «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» Федераль законның» сүзләрен «Россия Федерациясе Граждан кодексының, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» Федераль закон), башка федераль законнарның» сүзләренә алмаштырырга;

д) 11 өлештә «массакүләм мәгълүматның муниципальара басма чараларын» сүзләрен «муниципальара басма массакүләм мәгълүмат чарасын һәм челтәр басманы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 19 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тиешле вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында җирле бюджетларга бирелгән субвенцияләр чикләрендә җаваплы булалар.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән үзара эшчәнлеге турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Муниципаль берәмлекләр Советының идарә органнарын тәкъдим итүче затлар, шул исәптән муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар эшчәнлеге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә, шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы җирле үзидарә органнарына тапшырыла торган аерым дәүләт вәкаләтләренә караган мәсьәләләргә кагыла торган координация, киңәш бирү органнары һәм башка органнар составларына керергә хокуклы.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ статья өстәргә:

«$8^1$ статья. **Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең торышы һәм үсеше турында еллык доклад**

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең торышы һәм үсеше турында еллык доклад әзерли һәм аны 10 апрельдән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыра.».

**3 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, аның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 19 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән үзара эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен федераль законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән.

Шулай итеп, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон белән муниципальара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру тәртибе турында федераль законнарның нигезләмәләре төгәлләштерелде, Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советын төзү максатлары билгеләнде, әлеге совет тарафыннан Россия Федерациясе субъектында җирле үзидарәнең торышы һәм үсеше турында еллык доклад әзерләү турында нигезләмәләр кертелде.

Шулай ук, Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советының идарә органнарын тәкъдим итүче затларның эшчәнлеге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә, шулай ук Россия Федерациясе субъекты законнары белән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнары каршындагы җирле үзидарә органнарына тапшырыла торган аерым дәүләт вәкаләтләренә караган мәсьәләләргә кагыла торган координация, киңәш бирү органнары һәм башка органнар составларына керә алу хокукы билгеләнде.

Шуңа бәйле рәвештә закон проектында «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Закон проектында шулай ук Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең торышы һәм үсеше турында еллык докладның «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе тарафыннан һәр елның 10 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырылуы күздә тотыла (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы турында һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакындагы докладны тапшыру срогы белән тиңләштереп).

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 19 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән үзара эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 19 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән үзара эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 19 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән үзара эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 19 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән үзара эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.